ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Рәхмәт хаты турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2020 елның 9 июлендәге 483-VI ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Рәхмәт хаты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Рәхмәт хаты турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2020 елның 9 июлендәге 483-VI ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Рәхмәт хаты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктта «иҗтимагый берләшмә» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуар» сүзләрен өстәргә;

2) 15 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Комиссия гражданны Рәхмәт хаты белән бүләкләү турындагы үтенечнамәне әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында каралган нигезләрне, оешмадагы (индивидуаль эшкуардагы) эш стажын, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм (яисә) Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының бүләкләүләре һәм (яисә) бүләкләре булуны исәпкә алып карый.»;

3) 20 пунктта «тантаналы шартларда» сүзләрен «аңа кул куелган көннән алып бер ай эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

4) 21 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 18 ноябре
№ 1191-VI ДС